**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш. Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш. Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**« 25 » апрель 2025 ел** **№ 272**

**Әтнә муниципаль районы башлыгы Г.Г. Хәкимовның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсенең 6 пункты, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставының 40 маддэсе, Әтнә муниципаль районы башлыгы Габделәхәт Гыйлемхан улы Хәкимовның шәхси гаризасы нигезендә, Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Хәкимов Габделәхәт Гыйлемхан улының Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башлыгы вазыйфасыннан шәхси гаризасы нигезендә үз теләге белән китүен кабул итәргә.

2. Хәкимов Габделәхәт Гыйлемхан улының Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башлыгы вәкаләтләрен 2025 елның 25 апреленнән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасары –
Әтнә район Советы рәисе урынбасары Ф.М.Нуриев